КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 31 март г.Казань № 327

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 28 февраль, 137 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 28 февраль, 137 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 март, 176 нчы; 2023 ел, 3 ноябрь, 1416 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «275 статьясы» сүзләрен «$281^1$ статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта «275 статьясы» сүзләрен «$281^1$ статьясы» сүзләренә алмаштырырга,

«алар тарафыннан алынган керемнәр турында, аларның милек характерындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәт характерындагы бурычлары хакында мәгълүматлар, шулай ук үз ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары керемнәре турында, аларның милек характерындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәт характерындагы бурычлары хакында мәгълүматлар» сүзләрен «үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары хакында, шулай ук үз ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары керемнәре турында, мөлкәте турында һәм мөлкәт характерындагы бурычлары хакында мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан – «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының алар керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча.»

4 пунктта «хисап чорында (1 гыйнвардан алып 31 декабрьгә кадәр)» сүзләрен «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының алар керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан алып 31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин